РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

«23» октябрь 2019 с. Тюлячи № 590

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге № 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урыннарын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы буенча Россия ФКУ ҖБИ ФҖҮХИ Арча муниципальара филиалының 2019 елның 2 октябрендәге № 377 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге № 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урыннарын билгеләү турында»гы карарына (алга таба - карар) (2014 елның 27 гыйнварындагы 43 номерлы, 2016 елның 18 февралендәге 91 номерлы, 2016 елның 8 ноябрендәге 1012 номерлы, 2017 елның 11 июлендәге 422 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителгәннәрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эшләр төрләре исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 23 пунктны өстәргә:

| Объект атамасы | Эш төрләре |
|---|---|
| 23. ИП Мифтахов Н.Р. | - төяү-бушату эшләре;<br>- территорияләрне җыештыру;<br>- биналарны, корылмаларны, юлларны ремонтлау (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр;<br>- биналарны, корылмаларны, юлларны карап тоту эшләре. |

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов